**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 11 » октября 2021 с. Тюлячи № 262

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 мартындагы 139 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 06 сентябрендәге 1504 номерлы карары нигезендә Теләче муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 мартындагы 139 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» карарына (26.02.2020 № 69, от 11.05.2021 № 189 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Тәртибенә:

А) I бүлектә:

- 10 пунктны түбәндәге эчтәлекле "ж" һәм "з" пунктчалары белән тулыландырырга:

ж) дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт органнарыннан), җирле үзидарә органнарыннан, җирле администрация органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан контроль объекты эшчәнлегенә бәйле фактларны билгеләү һәм (яисә) раслау максатларында кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны соратып алырга;

з) дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт органнарыннан) җирле үзидарә органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнарыннан, шулай ук мәгълүмат системалары хуҗалары һәм (яки) операторлары булган оешмалардан, мәгълүмат системалары хуҗаларыннан һәм (яки) операторларыннан, мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт һәм башка саклана торган сер турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге мәгълүматка керү мөмкинлеген соратып алырга.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкчесе И.Х. Хәмидуллин